РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОРОК-САЙДАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫК САДАК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30 апрель 2021ел

№ 11

Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм
социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны
мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмдә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлегендә торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә.
2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлегендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.
3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Кырык Садак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2010 елның 20 февралендәге «Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм бирү нормасы турында» гы 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кырык Садак авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе В.Ф. Шагиева